РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

09.10.2024 | № 819-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм Саба муниципаль районында коткару хезмәтләрен булдыру турында» 2020 елның 05 мартындагы 359-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Гражданнар оборонасы буенча чараларны коткару хезмәтләре белән тәэмин итү максатларында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм Саба муниципаль районында коткару хезмәтләрен булдыру турында» 2020 елның 05 мартындагы 359-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында коткару хезмәтләрен формалаштыру һәм аларның эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 3.2.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту»;"

**2.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм Саба муниципаль районында коткару хезмәтләрен булдыру турында» 2020 елның 05 мартындагы 359-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

**3.** "5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гражданнар оборонасы буенча хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итүгә бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;

кешеләр күпләп була торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру;

Россия Федерациясенең бердәм электр элемтәсе челтәре чараларыннан, радио, чыбыклы һәм телевизион тапшырулар челтәрләреннән һәм чараларыннан, шулай ук мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплекслы файдалану;

мәгълүмат җыю һәм аны алмашу.».

**4.** 5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

**5.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Саба муниципаль районы
Гражданнар оборонасы җитәкчесе
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов